**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кармәт авыл җирлеге составына керуче Иске Кармәт торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**КАРАР**

2021 елның 29 ноябре № 1

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Иске Кармәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы нигезендә», Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кармәт авыл җирлеге Советының 2019 елның 5 ноябрендәге 101 номерлы «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кармәт авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары нигезендә, Аксубай муниципаль районы Иске Кармәт авыл җирлегендә 2021 елның 29 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде: "2022 елда һәр балигъ булган һәм Аксубай муниципаль районы Иске Кармәт авыл җирлеге Иске Кармәт торак пунктының территориясендә теркәлгән кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә (1 төркем инвалид, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш) һәм алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә килешәсезме?:

I. **Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

- Иске Кармәт авылы юлларына вак таш сатып алу;
- кышкы чорда юлларны карап тоту (Иске Кармәт авылының кышкы чорда юлларны кардан чистарту өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу).

**II. Җирлек халкының массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру һәм халык күпләп ял итә торган урыннарны җиһазландыруны оештыру, шул исәптән гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буе полосаларына иркле үтеп керүен тәэмин итү:**

- чишмәләрне ремонтлау (төзелеш һәм лак-буяу материаллары сатып алу).

**III. Каты коммуналь калдыклар җыю (шул исәптән аерым туплау) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнашу:**

- контейнер мәйданчыклары төзү (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

**IV. Территорияне төзекләндерү:**

- территорияне чабу һәм агачлар йоклау (бензокоса, бензопила, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу);
- трактор өчен асылмалы җиһазлар алу.

ӘЙЕ ЮК ТЫЕЛЫП КАЛДЫ"

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 284 граждан кертелгән, җыенда катнашучылар саны - 177 граждан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

- "әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 177 кеше тавыш бирде;

- җыенда катнашучы «юк» позициясе өчен 0 кеше тавыш бирде;

- “тыелып калам” позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Иске Кармәт авыл җирлеге составына керүче Иске Кармәт торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләре-чын мәгънәсендә.

2. "2022 елда һәр балигъ булган һәм Аксубай муниципаль районы Иске Кармәт авыл җирлеге Иске Кармәт торак пунктының территориясендә теркәлгән кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә (1 төркем инвалид, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш) һәм алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелгән алдагы эшләрне башкару буенча:

I. **Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

- Иске Кармәт авылы юлларына вак таш сатып алу;

- кышкы чорда юлларны карап тоту (Иске Кармәт авылының кышкы чорда юлларны кардан чистарту өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу).

**II. Җирлек халкының массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру һәм халык күпләп ял итә торган урыннарны җиһазландыруны оештыру, шул исәптән гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буе полосаларына ирекле үтеп керүен тәэмин итү:**

- чишмәләрне ремонтлау (төзелеш һәм лак-буяу материаллары сатып алу).

**III. Каты коммуналь калдыклар җыю (шул исәптән аерым туплау) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнашу:**

- контейнер мәйданчыклары төзү (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

**IV. Территорияне төзекләндерү:**

- территорияне чабу һәм агачлар йоклау (бензокоса, бензопила, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу);

- трактор өчен асылмалы җиһазлар алу.”

соравлары буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны Иске Кармәт авыл җирлегенең «Интернет» мәгълүмат–телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырылган рәсми сайтында: http://aksubaevo.tatar.ru, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кармәт авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru/ игълан итәргә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Аксубай
муниципаль районы Иске Кармәт
авыл җирлеге башлыгы

СОВЕТ СТАРОКИРЕМЕТСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

А.В.Парфенов